ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законының $2^1$ статьясына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 20 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында» 2006 елның 19 июнендәге 39-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының $2^1$ статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 6 (I өлеш); 2007, № 4; 2011, № 8 (I өлеш); 2012, № 12 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2015, № 5, № 10 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 27 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 51 (I өлеш); 2021, № 93 (I өлеш); 2022, № 34 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 өлешнең 1 пунктындагы бишенче абзацында «эшсез гражданнарга һәм» сүзләреннән соң «яраклы эш эзләү максатларында эш белән тәэмин итү хезмәте органнарында теркәлгән гражданнарга,» сүзләрен, «эшсез гражданнарга» сүзләреннән соң «һәм яраклы эш эзләү максатларында эш белән тәэмин итү хезмәте органнарында теркәлгән гражданнарга» сүзләрен өстәргә;

2) $3^1$ өлешкә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:
«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы хезмәт базары үзенчәлекләрен һәм эш эзләүче, эшли башларга әзер булучы һәм Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче гражданнар тарафыннан буш эш урыннарын һәм вакантлы вазыйфаларны биләү мөмкинлеген исәпкә алып, дәүләт программасын гамәлгә ашыру кысаларында хезмәткәрләр җәлеп ителми торган вазыйфалар, һөнәрләр, белгечлекләр исемлеген расларга хокуклы.»;

3) $3^3$ өлешнең 1 пунктында «эшсез гражданнарга» сүзләреннән соң «, яраклы эш эзләү максатларында эш белән тәэмин итү хезмәте органнарында теркәлгән гражданнарга» сүзләрен өстәргә;

4) 4 өлешнең 6 пунктындагы уникенче абзацында «эшсез гражданнарга һәм» сүзләреннән соң «яраклы эш эзләү максатларында эш белән тәэмин итү хезмәте органнарында теркәлгән гражданнарга,» сүзләрен, «эшсез гражданнарга» сүзләреннән соң «һәм яраклы эш эзләү максатларында эш белән тәэмин итү хезмәте органнарында теркәлгән гражданнарга» сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

Әлеге Закон 2023 елның 11 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2022 ел, 02 ноябрь
№ 77-ТРЗ